Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советының ундүртенче утырышы

Пановка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

31 март, 2022 ел № 36

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Ветеринария турында» Россия Федерациясе Законына, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 6 декабрендәге 397-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советының 2017 елның 15 декабрендәге 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (Советның 2018 елның 10 августындагы 101 номерлы, 2019 елның 5 апрелендәге 123, 2019 елның 8 маендагы 132, 2021 елның 16 августындагы 22 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 8 бүлекнең 8.15 пунктындагы «Йорт хайваннарын һәм кошларын тоту» 1 пунктчасында «терлекчелек продуктлары» сүзләрен «терлек продукциясе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев